| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 8 декабре № 27

Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 20 нче гыйнварындагы 1 нче нормерлы карары белән расланган Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Электрон рәвештә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә таләпләр турында»гы 2016 елның 26 мартындагы 236 нчы номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итә:**

1. Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 20 нче гыйнварындагы 1 нче нормерлы карары белән расланган Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.3.2.1 пунктның унберенче абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Формат-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан электрон формадагы һәр кырны тутыру процессында орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә автоматик рәвештә гамәлгә ашырыла. бердәм портал тарафыннан һәр запросның

электрон формасын тутыру процессында орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә автоматик рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал белән гарызнамәнең дөрес тутырылмаган электрон формасындагы кырын ачыклаганда мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында электрон формада мәгълүмати хәбәр аша хәбәр итә.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

Олы Ачасыр авыл жирлеге
башлыгы урынбасары М.Г. Гатиятуллин